ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КУЧУКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КӨЧЕК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

## ПОСТАНОВЛЕНИЕ

## КАРАР

06.02.2020

Түбән Көчек авылы

№ 4

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Көчек авыл җирлегендә гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ үткәрү тәртибен раслау турында

«Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законынын 23 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Көчек авыл җирлеге башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1. Кушымта итеп бирелгән Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Көчек авыл җирлегендә гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ үткәрү тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында http://agryz.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкчесе Р.Ә.НУРМУХӘМӘТОВ

Расланган
Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль айоны
Көчек авыл җирлеге
башкарма комитетының
06.02.2020 № 4
карары белән

**Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы**
**Көчек авыл җирлегендә гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә**
**анализ үткәрү тәртибе**

1. Әлеге Тәртип «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 23 статьясын үтәү йөзеннән эшләнде һәм Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының авыл җирлегендә гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрне (алга таба - мөрәҗәгатьләрне) гомумиләштерү һәм анализлау процедурасын билгели.

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Көчек авыл җирлегенә кергән гражданнар мөрәҗәгатьләрен анализлау язмача, электрон хәбәрләр рәвешендә, шулай ук Интернет-кабул итү, гражданнарны шәхси кабул итү барышында һәм телефон аша мөрәҗәгатьләрне исәпкә алып башкарыла.

3. Гражданнар мөрәҗәгатьләрен анализлау чоры елга ике тапкыр тәшкил итә: ярты ел эчендә һәм узган елда.

4. Һәр яртыеллык нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Көчек авыл җирлегенә кергән гражданнар мөрәҗәгатьләрен анализлау өчен җаваплы зат гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрне гомумиләштерә.

5. Анализ үз эченә түбәндәге мәгълүматны алырга тиеш:

- кергән, адресланган һәм каралган мөрәҗәгатьләр, шул исәптән телдән һәм язма мөрәҗәгатьләр саны, электрон документ формасында мөрәҗәгатьләрне дә кертеп;
- мөрәҗәгатьләр структурасы һәм тематикасы;
- шәхси кабул итү өчен җаваплы затларның шәхси кабул итүендә кабул ителгән гражданнар саны;
- мөрәҗәгатьләрне карау нәтиҗәләре, шул исәптән кабул ителгән норматив хокукый һәм башка актлар буенча кабул ителгән чаралар (булган очракта).

6. Гражданнар мөрәҗәгатьләрен гомумиләштерелгән анализ елга ике тапкыр Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында http://agryz.tatarstan.ru урнаштырыла.